Татарстан хөкүмәте Нури Сакаевка Хезмәт батыры дигән исемне бирә. Шуннан соң ул, Казан тамашачыларына тагын да якынаю теләге белән, Татар дәүләт академия театрында бөтенләйгә урнашып кала. Ләкин фаҗигале үлем бу матур тормышны өзә. 1927 елның 28 февралендә, генеральный репетициядән бушап, спектакль уйнарга җыенганда ул йөрәк параличыннан үлә.

Сакаевлар семьясыннан Нури аганың артист булып китүе очраклы хәл түгел. Алар бөтен семьялары белән җәмәгать хезмәткәрләре, алдынгы культура, сәхнә сәнгате вәкилләре булалар. Татар театрының үсүенә зур көч куйган бу семьяны телгә алганда, рус сәхнәсенең данын буыннан буынга саклап килүче Пров Садовскийлар семьясын искә төшерәсең.

Нури Сакаев, татар әсәрләрендә зур рольләрне тиңдәшсез уйнаган кебек, рус һәм дөнья классиклары әсәрләрендә дә үзен таныткан зур мастер. Шулай ук ул, баш рольләрне башкаруы белән берлектә, оста оештыручы, тәҗрибәле режиссер да иде. Аның бу хезмәте өзлексез үсә, киңәя барды. Бу хезмәт бигрәк тә гражданнар сугышы елларында, яшь совет театры өчен артистлар тәрбияләү эшендә үзенең нәтиҗәле җимешләрен бирде. Аның кул астында яшь артистларның бөтен бер буыны тәрбияләнеп үсте. Аның ярдәме белән татар совет сәхнәсендә Фатыйма Ильская кебек күренекле гүзәл талантлар җитеште.

Үзенең искиткеч таланты белән соңгы сулышына чаклы халыкка, партиягә турылыклы хезмәт күрсәткән зур сәхнә йолдызы Нури Сакаевны без бүген, формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культурабызның гөрләп чәчәк атуы көннәрендә, тирән ихтирам белән искә алабыз.

*(Мәкалә беренче тапкыр «Кызыл Татарстан» газетасында 1947, 7 мартта басылган — К. Г.).*

## Данлы гомер

*(РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисткасы Гөлсем Болгарскаяга 60 яшь һәм аның сәхнә эшчәнлегенә 41 ел тулу уңае белән)*

Татар сәхнәсенең беренче карлыгачларыннан берсе, талантлы актриса Гөлсем ханым Болгарскаяга шушы елның 15 октябрендә 60 яшь, аның сәхнә эшчәнлегенә 41 ел тула. Бу зур датаны сәнгать, театр эшчеләре, татар совет җәмәгатьчелеге хөрмәт белән каршы алалар. Чөнки 60 еллык гомернең кырык бер елын сәхнәдә уздыру — иҗат кешесе өчен зур горурлык ул.

Моннан кырык-кырык биш ел элек Гөлсемнең ата-аналары кызларының халыкка шундый зур хезмәт күрсәтәчәге турында хәтта башларына да китерә алмаганнардыр.

1905 елгы буржуаз-демократик революция татар җәмәгать фикеренең үсешенә уңай, зур йогынты ясап, күп кенә яшьләрне гыйлемгә, аң-белем мәйданына тартып чыгара. Бу революция күп кенә яшьләрне дин, иске гореф-гадәтләр, йолалар сөременнән арындырып, прогрессив әдәбият, сәнгать һәм культураның башка тармаклары аша халыкка хезмәт итү идеясе белән коралландыра. Нәкъ әнә шул прогрессив идея белән рухланган алты татар егете, 1906 елның башында, Оренбург шәһәрендә, учитель Ильяс Кудашев-Ашказарский кул астында кечкенә генә труппа төзеп, шәһәрдән шәһәргә спектакльләр куеп йөрергә чыгып китә. Труппаның артистлары ачлык-ялангачлык кичереп, төрле газаплар күреп Идел буендагы күп кенә шәһәрләрдә булалар. Алар хәтта Мәскәү шәһәренә кадәр барып җитәләр. Бу кыю егетләрнең һәм беренче татар артисткасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская хезмәтләре нәтиҗәсез калмый. Татар яшьләре арасында чын-чынлап татар театрын тудыру идеясе кузгала. Ниһаять, бер елдан соң инде Казан, Уфа, Астрахань шәһәрләрендә дә профессиональ театрлар барлыкка киләләр.



*Гөлсем Болгарская һәм аның ире Хәмит Колмәмәт.*

Татарча спектакльләр Казанда, кайбер морзаларның өйләрендә, учительская школада һәм мәдрәсә шартларында 1883 еллардан ук булгалап килсә дә, тар даирәләрдә уйналган бу спектакльләр семья зәвыгын канәгатьләндерүдән ерак китә алмаганнар. Киң халык катлавын тәрбия итүне үзенә максат итеп куйган профессиональ театр Казанда тик 1907 елда гына барлыкка килә һәм бу коллектив үзен «Сәйяр труппасы» дип исемли. Бу театр тиз арада популярлашып, халыкның мәхәббәтен казана, культурага, аң-белемгә сусаган татар яшьләрен үзенә тарта.



Чыганак: Гыйззәтов, К. Таҗи Гыйззәт. Фикерләр. Истәлекләр, Хатлар. Бәхәсләр.- Казан: Мастер Лайн, 2000.- 512 б.

Искерәк фикерле ата-аналарыннан төрле хәйлә юллары белән ычкынып, үзенең Зәйнәп исемле иптәш кызы ярдәмендә «Сәйяр» труппасының 1910 ел июнь аенда «Эрмитаж» бакчасында уйналган спектакленә, ниһаять, Гөлсем дә килә.

Ике дус кыз – Гөлсем белән Зәйнәп – театр башланганны түземсезлек белән көтеп, үзләре шулай да кеше-карага күренмәскә тырышып (чөнки Гөлсемнең ата-аналарына җиткерүдән куркалар), аулаграк урынга, агачлар арасына кереп утыралар.

Тора-бара халык та җыела. Хатыннарын ияртеп сәүдәгәрләр, приказчиклар, эшчеләр, һөнәрчеләр, рус мәктәпләрендә укучы кызлар, егетләр күренгәлиләр.

Афишада игълан ителгән вакыт күптән үтеп китә, караңгы төшә башлый. Ләкин артистлар ни өчендер спектакльне башламыйлар да башламыйлар. «Сәйяр» труппасында Фәхрия исемле апасы катнашып йөргәнлектән, Зәйнәп батыраеп һәм спектакльне нишләп башламауларының сәбәбен белергә тырышып, Гөлсемне җәйге театрның сәхнә артына алып керә һәм сәхнә артында ыгы-зыгы килеп йөрүче артистлар белән таныштыра башлый. Театрның җитәкчесе Гөлсем белән күрешкәндә, андагы кыюлык, тәвәккәллек сыйфатларын күреп ала да, аңа:

– Сез, туташ, безне бер бәладән коткара алмыйсызмы? – дип сорау бирә.

Кыскасы, билгесез сәбәп белән килмичә калган артистка урынына чыгып уйнарга Гөлсемгә тәкъдим ясала. Гөлсем, әлбәттә, риза булмый, үзенең гомерендә беренче тапкыр театр карарга килүен белдерә. Ләкин артистлар төрле яктан аны сырып алалар, уйнарга димлиләр. Ахырында Гөлсемне күндерәләр. Пьеса буенча, аның роле икенче пәрдәдә генә була. Беренче пәрдә уйналган арада аны киендерәләр, грим салалар, сәхнәнең кайбер шартларын өйрәтәләр.

...Рольне тәмам итеп сәхнә артына чыгуга, театрның җитәкчесе йөгереп килә дә:

– Туташ, билләһи дип әйтәм, сез – артистка, чын артистка булачаксыз! – дип Гөлсемнең кулын кыса.

Чын йөрәктән әйтелгән бу сүзләр дөрескә чыга, Гөлсем Мостафина (Болгарская) шул көннән артистка булып китә.

Әнә шулай очраклы шартларда башланып киткән хезмәткә быел кырык ел тулды. шул кырык бер еллык сәхнә хезмәте Гөлсем ханым Болгарскаяга дан, шөһрәт китерде, аны татар совет сәхнәсенең атаклы артисткасы булу дәрәҗәсенә ирештерде.



Гөлсем Болгарская сәхнәгә чыккан заманнарда артист булу, бигрәк тә артистка булу зур тәвәккәллек, искиткеч кыюлык таләп итә иде. Чөнки ул чордагы карагруһ байлар, муллалар карашынча, театрда уйнау бик зур гөнаһ исәпләнә, татар хатын-кызлары өчен аеруча түбәнлек итеп карала иде. Гөлсем Болгарскаяга гадәттән тыш авырлыкларны кичерергә туры килә. Итче, толчокчы мулла-мунтагайларның төрле әшәке сүзләр белән кычкырып калуларына карамыйча, ул үзе сайлаган юлдан бер генә адым да чигенмичә барып, халыкка хезмәт итә, үзенең гомерен шул эшкә багышлый.

Гөлсем Болгарскаяның бер сәхнә бәйрәме уңае белән, атаклы драматургыбыз Галиәсгар Камал, артистлардан Касыйм Шамил, Нәфига Арапова, Габдрахман Камал һәм башка артистлар тарафыннан аңа бирелгән адреста: «Сез иске гадәт-йолаларны җимереп, сәхнәгә чыктыгыз да хатын-кыз галәменең азатлык тарихында үзегезгә аерым рәвештә исем алуга ирештегез», дип язылган сүзләр бик тә урынлы.

Гөлсем Болгарская үз иҗатын милли рамкалар калыбында гына калдырмыйча, бөек рус драматургы Островскийның «Гроза»сында Катерина, немец шагыйре Шиллернең «Мәкер һәм мәхәббәт» әсәрендә Луиза рольләрен уйнап, талантын һаман киңәйтә, артистлык осталыгын үстерә килә.

Бөек Октябрь социалистик революциясен Гөлсем ханым Болгарская һичбер икеләнүсез һәм гаять көчле иҗат энтузиазмы белән каршы ала. Гражданнар сугышы елларында кайбер иске артистлар, аумакайлык күрсәтеп, яктан-якка йөргәндә, Гөлсем Болгарская үз халкыннан, бөек коммунистлар партиясе җитәкчелегендә эшчеләр һәм хезмәт иясе крестьяннар алып барган зур вакыйгалардан һич тә аерылмый. Революциядән соң ук оештырылган беренче спектакльдә катнашучы артистлар арасында беренче булып аның исем-фамилиясе тора. Һәм шул елны төзелгән беренче Татар совет театрының составына беренче булып Гөлсем Болгарская язылды. Совет театрының 34 еллык чорында без аның бик аз гына вакытка да театрдан аерылмыйча яшәвен, шул театр белән бергә көннән-көн үсә баруын күрәбез.

Гөлсем ханым Болгарская иҗат иткән образлар күп һәм төрле. Аларның саны берничә йөзләр белән исәпләнә. Газета мәкаләсендә аларның һәркайсына аерым-аерым тукталырга мөмкин булмаганлыктан, аларның кайберләрен генә әйтеп китү белән чикләнергә туры килә.

Революциягә кадәр иҗат иткән образларыннан менә «Бүләк өчен» әсәрендәге Хәмидә – бер кулмәк өчен үз баласын бәхетсез

итәргә йөрүче түбән аңлы «мал колы». «Беренче театр»да ахмак ире белән бимазаланып беткән уңган килен Факиһә. «Банкрот» әсәрендә аферист сәүдәгәр хатыны мактанчык Гөлҗиһан. «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясендә Юныс хаҗи хатыны хәйләкәр Галимә. «Галиябану» драмасында — саф йөрәкле, туры фикерле крестьян хатыны Галимәбану һәм башка, һәм башка образлары белән алдыбызда чын реалистик образлар галереясы булып тезелеп торалар.

Гөлсем Болгарскаяның иҗаты Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соңгы чорда аеруча тармакланып чәчәк атты. Ул бары тик Октябрь революциясеннән соң гына үз иҗатына чын мәгънәсендә киң мәйдан таба алды. Хезмәт иясе кешеләренең чын образларын Октябрьдан соң гына тудырды.

Менә «Бишбүләк» әсәрендә ул тудырган Мәрфуга карчык образы. Бу рольдә Болгарская уйнамый, ә чын-чыннан яши. Баласы өчен чын күңелдән янган ананың катлаулы кичерешләрен ул тирән мәхәббәт яктысында тамашачылар алдына китереп бастыра.

«Изге әманәт» әсәрендә немец фашистларына тирән нәфрәт саклаучы горур карчык Хәзинә. «Тормыш җыры» әсәрендә Шәйхулла бабайның ягымлы, изге күңелле карчыгы Мәргубә әби. Яки менә быелгы сезонда иҗат иткән Маркелова роле («Икенче мәхәббәт»), «Ялгыз каен»дагы Гөлбәдәвәм карчык һәм башка, һәм башка образларда Гөлсем Болгарскаяның зур таланты үзен яңадан-яңа яклары белән күрсәтә.

Ялкынлы шагыйрь Гадел Кутуй Гөлсем ханым Болгарскаяның утыз еллык сәхнә хезмәтен искә алып язган мәкаләсендә болай дип әйтеп киткән иде: «Никадәр күп образлар... «Гроза» әсәрендә Кабаниха, «Чаткылар»да Чикерткә Гыйльменисасы, «Гаепсездән гаепләләр»дә Кручинина, «Гамлет»та — Королева, «Дошманнар»да Полина, «Яшь гомер»дә Шәмсенисалар... Йөзләрчә образлар... Том-том ятлаган рольләр... Озын төннәр буе йокламыйча тудырган иҗат үрнәкләре бер-бер артлы күз алдыннан үтеп китәләр...»

Шулай итеп, сәхнәдә узган кырык бер еллык хезмәт, Гөлсем ханым Болгарскаяга елдан-ел яңа иҗат казанышлары биреп, аны совет сәнгатенең данлыклы артисткасы булу дәрәҗәсенә китерде. Аның бу гүзәл иҗат тормышы театрның башка артистларына үрнәк булып тора.

Гөлсем Болгарская, сәхнәдә зур тырышлык күрсәтеп уйнавы белән бергә, актив җәмәгать эшчесе дә. Ул театрда, сәнгать эшчеләре профсоюзында, Совет Армиясенә шефлык комиссиясендә, кыскасы, берничә төрле җәмәгать эше алып бара.



1946 елны Гөлсем Болгарскаяның тормышында бик зур вакыйга була, ул 55 яшендә ВКП(б) сафына керә. Хәзерге көндә ул зур тырышлык белән үзенең политик белемен күтәрү өстендә эшли. Партия мәгарифе буенча театрда оештырылган түгәрәкләрдә иң актив катнашучылардан берсе — Гөлсем ханым Болгарская.

Совет хөкүмәте һәм партиябез, Гөлсем Болгарскаяның ил һәм халык алдындагы зур хезмәтләрен искә алып, аңа Татарстанның халык артисткасы һәм РСФСРның атказанган артисткасы дигән хөрмәтле исемнәрне бирделәр, ул «Почет билгесе» ордены һәм «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнде.

Өлкән буын артистларыннан берсе булган талантлы артисткабыз Гөлсем Болгарскаяга озын гомер һәм татар совет сәхнәсендә яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.

*(Мәкалә беренче тапкыр «Кызыл Татарстан» газетасында 1951, 14 октябрендә басыла — К. Г.).*

## Күренекле драматург

Драматург Риза Ишморатның тууына илле ел, татар совет драматургиясе өлкәсендә эшләвенә егерме биш ел тулды. Риза Ишморат, шушы чирек гасырда татар совет театрлары өчен егермедән артык драма әсәре биреп, театр сәнгатебезне, әдәбиятыбызны үстерүдә күп хезмәт күрсәткән драматург.



*Драматург Риза Ишморатның Т. Гыйззәткә Вена (Австрия) шәһәреннән җибәргән фоторәсеме. 1946 ел, март ае.*

Аның әсәрләре Татар дәүләт академия театры, башкорт дәүләт академия театры һәм колхоз-совхоз театрлары сәхнәләрендә, меңнәрчә үзешчән сәнгать түгәрәкләре тарафыннан куела, миллионнарча тамашачылар тарафыннан зур ихтирам белән карала. Р.Ишморатның «Ун ел тулганда», «Пожар», «Данлы чор», «Ил өчен», «Кайту», «Якты юл», «Якын дус», «Бистә кызы Гөлсинә» кебек әсәрләре зур уңыш казандылар.

Риза Фәхретдин улы Ишморатов 1903 елның 1 ноябрендә Татарстан республикасының Актаныш